**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 13 апрелендәге 1193 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2023 елның 4 сентябрендәге 2548 номерлы**
**«“2024-2026 елларга Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтне үстерү” муниципаль программасы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында кадрлар сәясәтен камилләштерү максатыннан, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 8 августындагы 4720 номерлы «Казан шәһәре муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 4 сентябрендәге 2548 номерлы «“2024-2026 елларга Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтне үстерү” муниципаль программасы турында»гы карары кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. программа паспортында «Программаны елларга бүлеп финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бирергә:

| | |
|---|---|
| «Программаны елларга бүлеп финанслау күләмнәре | Программаны Казан шәһәре бюджеты акчалары хисабына финанслауның гомуми күләме 46 572,9 мең сумны тәшкил итә, шул исәптән:<br>2024 елда – 16 960,3 мең сум;<br>2025 елда – 16 305,6 мең сум;<br>2026 елда – 13 307,0 мең сум» |

1.2. III бүлекне түбәндәге редакциядә бирергә:

«III. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программа чаралары Казан шәһәре бюджеты акчалары хисабына гамәлгә ашырыла. Программаны 2024-2026 елларга финанслау күләме 46 572,9 мең сумны тәшкил итә, шул исәптән:

- 2024 елда – 16 960,3 мең сум;
- 2025 елда – 16 305,6 мең сум;
- 2026 елда – 13 307,0 мең сум.

Программаның «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын үтәү кысаларында гамәлгә ашырыла торган чаралары күрсәтелгән дәүләт программасы белән каралган ассигнованиеләр күләмнәрендә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына финанслана.

Бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, Программаны гамәлгә ашыруга юнәлдерелә торган акчалар күләме чираттагы финанс елына Казан шәһәре бюджеты проектын эшләгәндә төгәлләштерелә»;

1.3. Программага 1 һәм 2 номерлы кушымталарны әлеге карарга 1 һәм 2 номерлы кушымталар нигезендә редакцияләргә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алиевка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 13 апрелендәге
1193 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

## Максатчан финанслауны таләп итми торган оештыру характерындагы һәм норматив-хокукый характердагы чаралар

| № т/б | Төп чара атамасы | Башкаручылар | Чаралар-ны үтәү вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Индикатор күрсәткечләре | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2023 ел (база елы) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел |
| 1 нче максат: Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан үзләренә йөкләнгән вәкаләтләрне башкару нәтиҗәлелеген арттыру | | | | | | | | |
| 1 нче бурыч: Җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең, шул исәптән аларның оештыру структурасын һәм штат санын камилләштерү аша, нәтиҗәлелеген арттыру | | | | | | | | |
| 1.1.1 | Җирле үзидарә органнары структурасына анализ ясау | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Казан шәһәре Думасы (килешү буенча), Казан шәһәренең контроль-хисап палатасы (килешү буенча) | 2024 ел | Җирле үзидарә органнары структурасын анализлау нәтиҗәләре буенча хисап әзерләү, аларны камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертү | | + | | + |
| 1.1.2 | Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Казан шәһәре Думасы | 2024-2026 еллар | Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасында җирле үзидарә органнарының һәм | + | + | + | + |

| № т/б | Төп чара атамасы | Башкаручылар | Чаралар-ны үтәү вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Индикатор күрсәткечләре | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2023 ел (база елы) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел |
| | кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасында кадрлар эшен алып баруны тәэмин итү | (килешү буенча), Казан шәһәренең контроль-хисап палатасы (килешү буенча) | | муниципаль органның кадрлар составын характерлаучы актуаль белешмәләр булу | | | | |
| 2 нче бурыч: Муниципаль хезмәткәрләрне сайлап алуның, эшчәнлекләрен комплекслы бәяләүнең һәм аларны хезмәт урынында үстерүнең нәтиҗәле механизмнарын гамәлгә кертү | | | | | | | | |
| 1.2.1 | Муниципаль хезмәткәрләрнең идарә итү компетенцияләрен бәяләүне уздыруга юнәлтелгән чараларны гамәлгә ашыру | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты | 2024-2026 еллар | Муниципаль хезмәткәрләрнең идарә итү компетенцияләрен бәяләүне уздыру | + | + | + | + |
| 1.2.2 | Корпоратив культураны, Казан шәһәре җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре белән эшләүдә бердәм алымнарны гамәлгә кертүдә һәм үстерүдә ярдәм күрсәтү | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Казан шәһәре Думасы (килешү буенча), Казан шәһәренең контроль-хисап палатасы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | Корпоратив культураны, Казан шәһәре җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре белән эшләүдә бердәм алымнарны гамәлгә кертү турында хисап | + | + | + | + |
| 1.2.3 | Җирле үзидарә органнарында, шул исәптән муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә һөнәри белем бирү системасы | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Казан шәһәре Думасы (килешү буенча), | 2024-2026 еллар | Муниципаль хезмәткәрләргә җирле үзидарә органнарында ике стажировка уздыру | 2 | 2 | 2 | 2 |

| № т/б | Төп чара атамасы | Башкаручылар | Чаралар-ны үтәү вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Индикатор күрсәткечләре | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2023 ел (база елы) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел |
| | кысаларында муниципаль хезмәткәрләр өчен стажировка мәйданчыклары оештыру | Казан шәһәренең контроль-хисап палатасы (килешү буенча) | | | | | | |
| 1.2.4 | Җирле үзидарә органнары эшчәнлегендә цифрлы кадрлар платформасын гамәлгә кертү һәм аның эшләвен тәэмин итү | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Казан шәһәре Думасы (килешү буенча), Казан шәһәренең контроль-хисап палатасы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | Цифрлы кадрлар платформасы булу | | + | + | + |
| 1.2.5 | Вакантлы муниципаль хезмәт вазифалары турында мәгълүматны һәркем файдалана ала торган интернет-ресурсларда урнаштыру | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Казан шәһәре Думасы (килешү буенча), Казан шәһәренең контроль-хисап палатасы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | Түбәндәге интернет-ресурсларда вакантлы муниципаль хезмәт вазифалары турында актуаль мәгълүмат булу:<br>1) Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталы (www.kzn.ru);<br>2) «Работа в России» федераль дәүләт мәгълүмат системасы | + | + | + | + |
| 1.2.6 | Хезмәткә яңа кабул ителгән муниципаль хезмәткәрләр өчен адаптация һәм | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур | 2024-2026 еллар | Җирле үзидарә органнарының хезмәткә яңа алынган муниципаль хезмәткәрләре өчен адаптация һәм остазлык мәсьәләләрен җайга сала | + | + | + | + |

| № т/б | Төп чара атамасы | Башкаручылар | Чаралар-ны үтәү вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Индикатор күрсәткечләре | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2023 ел (база елы) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел |
| | остазлык системасын камилләштерү | бүлекчәләре, Казан шәһәре Думасы (килешү буенча), Казан шәһәренең контроль-хисап палатасы (килешү буенча) | | торган актуаль муниципаль норматив хокукый акт булу | | | | |
| 1.2.7 | Аттестация үткәргәндә, шулай ук кадрлар резервларын формалаштырганда, муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук муниципаль хезмәт вазифаларын биләүгә дәгъва кылучы затларның һөнәри белемнәрен һәм осталыкларын бәяләү ысулларын камилләштерү | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Казан шәһәре Думасы (килешү буенча), Казан шәһәренең контроль-хисап палатасы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | Аттестация үткәргәндә һәм кадрлар резервларын формалаштырганда, муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук муниципаль хезмәт вазифаларын биләүгә дәгъва кылучы затларның һөнәри белемнәрен һәм осталыкларын бәяләүдә яңа инструментлар булу һәм алардан файдалану | + | + | + | + |
| 3 нче бурыч: Муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук кадрлар резервына кертелгән затларның һөнәри яктан һәм идарә итү компетентлыгын үстерү | | | | | | | | |
| 1.3.1. | Семинарлар оештыру һәм, җирле үзидарә органнары өчен күчмә консультацияләрдә катнашу максатыннан, хезмәткәрләр юллау | Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Казан шәһәре Думасы (килешү буенча), Казан шәһәренең контроль-хисап палатасы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | Җирле үзидарә органнары өчен уздырылган чаралар, семинарлар, күчмә консультацияләр саны | 5 | 6 | 7 | 8 |

| № т/б | Төп чара атамасы | Башкаручылар | Чараларның үтәү вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Индикатор күрсәткечләре | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2023 ел (база елы) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел |
| 4 нче бурыч: Муниципаль хезмәттә мотивацияләүнең, стимуллаштыруның нәтиҗәле системасын төзү, җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре өчен клиент ихтыяҗларын канәгатьләндерү сервисларын үстерү | | | | | | | | |
| 1.4.1. | Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү системасын камилләштерү | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты | 2024-2026 еллар | Хезмәт өчен түләү турында муниципаль хокукый актлар кабул итү | + | + | + | + |
| 5 нче бурыч: Яшь, перспективалы белгечләрне муниципаль хезмәткә җәлеп итү һәм беркетү | | | | | | | | |
| 1.5.1 | Муниципаль хезмәтнең максатлары һәм бурычлары турындагы мәсьәләләрне яктыртып, югары һәм һөнәри белем бирү оешмалары студентлары өчен ачык очрашулар, семинарлар, түгәрәк өстәлләр үткәрү | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Казан шәһәре Думасы (килешү буенча), Казан шәһәренең контроль-хисап палатасы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | Үткәрелгән семинарлар, түгәрәк өстәлләр саны | 10 | 15 | 15 | 15 |
| 1.5.2 | Югары һәм һөнәри белем бирү оешмалары белән төзелә торган килешүләр нигезендә студентларны җирле үзидарә органнарына практикага (стажировкага) кабул | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Казан шәһәре Думасы (килешү буенча), Казан шәһәренең контроль-хисап палатасы (килешү | 2024-2026 еллар | Югары һәм һөнәри белем бирү оешмалары белән төзелә торган килешүләр нигезендә студентларны практикага (стажировкага) кабул иткән җирле үзидарә органнары өлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 |

| № т/б | Төп чара атамасы | Башкаручылар | Чаралар-ны үтәү вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Индикатор күрсәткечләре | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2023 ел (база елы) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел |
| | итү эшен оештыру | буенча) | | | | | | |
| 1.5.3 | Муниципаль хезмәткәрләрнең эшчәнлеге турындагы мәгълүматны массакүләм мәгълүмат чараларында, җирле үзидарә органнарының Интернет челтәрендәге рәсми сайтларында бастырып чыгару | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Казан шәһәре Думасы (килешү буенча), Казан шәһәренең контроль-хисап палатасы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | Муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлеге, муниципаль хезмәтне үстерү турында массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарылган, Интернет челтәрендә җирле үзидарә органнарының рәсми сайтларында урнаштырылган статьялар һәм башка мәгълүмати-аналитик материаллар булу | + | + | + | + |
| 6 нчы бурыч: Җәмәгать контроле һәм гражданлык җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлек системасын үстерү, муниципаль хезмәттә коррупциягә каршы чараларны гамәлгә ашыру | | | | | | | | |
| 1.6.1 | Муниципаль хезмәт вазифаларын биләүгә дәгъва кылучылар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт белән бәйле таләпләрнең, чикләүләрнең һәм тыюларның, шул исәптән коррупциягә каршы көрәш турындагы | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Казан шәһәренең контроль-хисап палатасы (килешү буенча), Казан шәһәре Думасы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | Тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча хисаплар булу | + | + | + | + |

| № т/б | Төп чара атамасы | Башкаручылар | Чаралар-ны үтәү вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Индикатор күрсәткечләре | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2023 ел (база елы) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел |
| | законнарның үтәлешен тикшерүне оештыру | | | | | | | |
| 1.6.2 | Җирле үзидарә органнары коллективлары өчен муниципаль хезмәт ветераннары, төрле юнәлешләр буенча шәһәр берләшмәләре, иҗтимагый берләшмәләр, махсус хәрби операциядә катнашучылар белән очрашулар оештыру | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Казан шәһәренең контроль-хисап палатасы (килешү буенча), Казан шәһәре Думасы (килешү буенча) | 2026 ел | Үткәрелгән очрашулар саны | - | - | - | 2 |
| 7 нче бурыч: Муниципаль хезмәтне норматив һәм методик яктан тәэмин итү | | | | | | | | |
| 1.7.1 | Муниципаль хезмәт турындагы законнар белән каралган таләпләрнең үтәлешен анализлау, персонал белән идарә итүнең заманча технологияләренә юнәлеш тотып, кадрлар эшен камилләштерү | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, ККазан шәһәренең контроль-хисап палатасы (килешү буенча), Казан шәһәре Думасы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | Муниципаль хезмәт турындагы законнар белән каралган таләпләрнең, кадрлар эшенең үтәлешен анализлау нәтиҗәләре булу һәм кирәкле чаралар күрү | + | + | + | + |

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 13 апрелендәге
1193 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

## Программаның максаты, бурычлары, аны гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм Программа чараларын финанслау

| № т/б | Төп чара атамасы | Башкаручылар | Төп чара-ларны башкару вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Индикатор күрсәткечләре | | | | Җирле бюджет чаралары (ТР бюджеты) хисабына финанслау, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2023 ел (база елы) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2023 ел (база елы) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел |
| 1 нче максат: Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан үзләренә йөкләнгән вәкаләтләрне башкару нәтиҗәлелеген арттыру | | | | | | | | | | | | |
| 2 нче бурыч: Муниципаль хезмәткәрләрне сайлап алуның, эшчәнлекләрен комплекслы бәяләүнең һәм аларны хезмәт урынында үстерүнең нәтиҗәле механизмнарын гамәлгә кертү | | | | | | | | | | | | |
| 1.2.8 | Эшкә урнаштыру өчен кандидатлар эзләү цифрлы сервисын, элеккеге хезмәткәрләрнең фикерләре белән эшләү сервисын гамәлгә кертү һәм эштә файдалану | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Казан шәһәре Думасы (килешү буенча), Казан шәһәренең контроль-хисап | 2024-2026 еллар | Казан шәһәренең җирле үзидарә органнарында булган вакансияләргә җавап бирүчеләрнең гомуми саны | 15 000 | 15 000 | 15 000 | 15 000 | - | - | 1 338,4 | - |

| № т/б | Төп чара атамасы | Башкаручылар | Төп чара-ларны башкару вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Индикатор күрсәткечләре | | | | Җирле бюджет чаралары (ТР бюджеты) хисабына финанслау, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2023 ел (база елы) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2023 ел (база елы) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел |
| | | палатасы (килешү буенча) | | | | | | | | | | |
| 3 нче бурыч: Муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук кадрлар резервына кертелгән затларның һөнәри яктан һәм идарә итү компетентлыгын үстерү | | | | | | | | | | | | |
| 1.3.1 | Муниципаль хезмәткәрләрнең һәм муниципаль вазифаларны биләүче затларның квалификация-сен күтәрүне, аларны һөнәри яктан яңадан әзерләүне оештыру | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Казан шәһәре Думасы (килешү буенча), Казан шәһәренең контроль-хисап палатасы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | Тиешле елда квалификация күтәрү, һөнәри яктан яңадан әзерләү курслары узган муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль вазифалар биләүче затлар өлеше, % | 30 | 30 | 40 | 40 | ТР бюд-жеты | ТР бюд-жеты | ТР бюд-жеты | ТР бюд-жеты |
| 1.3.2 | Җирле үзидарә органнарында Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе субъектларының дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләре өчен стажировка | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Казан шәһәре Думасы (килешү | 2024-2026 еллар | Җирле үзидарә органнарында Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе субъектларының дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләре өчен | 9 | 10 | 10 | 10 | - | 67,4 | 85,0 | - |

| № т/б | Төп чара атамасы | Башкаручылар | Төп чара-ларны башкару вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Индикатор күрсәткечләре | | | | Җирле бюджет чаралары (ТР бюджеты) хисабына финанслау, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2023 ел (база елы) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2023 ел (база елы) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел |
| | мәйданчыгы оештыру | буенча), Казан шәһәренең контроль-хисап палатасы (килешү буенча) | | оештырылган стажировкалар саны | | | | | | | | |
| 1.3.3 | Казан шәһәренең җирле үзидарә органнарында студентлар өчен стажировка оештыру | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты | 2024-2026 еллар | Сан, кеше (стажировка узучылар) | 37 | 35 | 35 | 35 | - | 837,0 | 710,0 | 930,0 |
| 1.3.4 | Казан шәһәренең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре өчен түгәрәк өстәлләр, стратегик сессияләр, белем бирү лекцияләре, семинарлар һәм интенсивлар оештыру һәм үткәрү | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты | 2024-2026 еллар | Үткәрелгән чаралар саны | 12 | 15 | 15 | 9 | - | 500,0 | - | - |
| 1.3.5 | Яшь хезмәткәрләр өчен уку-укыту интенсивын оештыру һәм үткәрү | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты | 2026 ел | Үткәрелгән чаралар саны | - | - | - | 1 | - | - | - | - |

| № т/б | Төп чара атамасы | Башкаручылар | Төп чара-ларны башкару вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Индикатор күрсәткечләре | | | | Җирле бюджет чаралары (ТР бюджеты) хисабына финанслау, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2023 ел (база елы) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2023 ел (база елы) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел |
| 4 нче бурыч: Муниципаль хезмәттә мотивацияләүнең, стимуллаштыруның нәтиҗәле системасын төзү, җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре өчен клиент ихтыяҗларын канәгатьләндерү сервисларын үстерү | | | | | | | | | | | | |
| 1.4.1 | Ел саен үткәрелә торган «Казан шәһәре Мэриясенең ел командасы» конкурсын оештыру һәм тиешле республика һәм бөтенроссия конкурсларында катнашуга тәкъдим итү | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Казан шәһәре Думасы (килешү буенча), Казан шәһәренең контроль-хисап палатасы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | Муниципаль хокукый акт кабул итү һәм «Казан шәһәре Мэриясенең ел командасы» конкурсын үткәрү | + | + | + | + | - | 1 709,4 | 2 618,5 | - |
| 1.4.2 | Муниципаль хезмәткәрләрнең сәламәтлегенә зыян килү очраклары өчен мәҗбүри дәүләт иминиятләштерү системасын булдыру | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Казан шәһәре Думасы (килешү буенча), | 2024-2026 еллар | Муниципаль хезмәткәрләрнең сәламәтлегенә зыян килү очраклары өчен мәҗбүри дәүләт иминиятләштерү чараларын оештыру | + | + | + | + | 4 698,9 | 4 543,0 | 3853,2 | 5 957,0 |

| № т/б | Төп чара атамасы | Башкаручылар | Төп чара-ларны башкару вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Индикатор күрсәткечләре | | | | Җирле бюджет чаралары (ТР бюджеты) хисабына финанслау, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2023 ел (база елы) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2023 ел (база елы) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел |
| | | Казан шәһәренең контроль-хисап палатасы (килешү буенча) | | | | | | | | | | |
| 1.4.3 | Муниципаль хезмәткәрләргә диспансеризация үткәрү | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Казан шәһәре Думасы (килешү буенча), Казан шәһәренең контроль-хисап палатасы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | Диспансериза-ция узган хезмәткәрләр саны | 2159 | 2204 | 1892 | 1892 | 6 439,0 | 6 479,0 | 4614,0 | 5 350,0 |
| 1.4.4 | Казан шәһәренең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре арасында «Команда горурлыгы» проектын гамәлгә ашыру | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Казан шәһәре | 2024-2026 еллар | Җирле үзидарә органнарында үткәрелгән «Команда горурлыгы» конкурслары саны (катнашучылар саны – 60 кешегә кадәр), ярты елга | 2 | 2 | 2 | 2 | - | 220,0 | 220,0 | - |

| № т/б | Төп чара атамасы | Башкаручылар | Төп чара-ларны башкару вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Индикатор күрсәткечләре | | | | Җирле бюджет чаралары (ТР бюджеты) хисабына финанслау, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2023 ел (база елы) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2023 ел (база елы) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел |
| | | Думасы (килешү буенча), Казан шәһәренең контроль-хисап палатасы (килешү буенча) | | бер тапкыр | | | | | | | | |
| 1.4.5 | Казан шәһәренең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре өчен коммуникатив сессияләр, интеллектуаль турнирлар оештыру | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Казан шәһәре Думасы (килешү буенча), Казан шәһәренең контроль-хисап палатасы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | Үткәрелгән коммуникатив сессияләр, интеллектуаль турнирлар саны | 4 | 4 | 4 | 4 | - | - | 992,8 | - |
| 1.4.6 | Җирле үзидарә көненә хезмәткәрләр өчен чаралар оештыру | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты | 2024-2026 еллар | Тантаналы чаралар үткәрү | + | + | + | + | - | 1 141,0 | 950,5 | 555,5 |
| 1.4.7 | «Кадрлар» илкүләм проекты | Казан шәһәре Башкарма комитеты | 2025-2026 еллар | Үткәрелгән очрашулар саны | - | - | 4 | 4 | - | - | 320,0 | - |

| № т/б | Төп чара атамасы | Башкаручылар | Төп чара-ларны башкару вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Индикатор күрсәткечләре | | | | Җирле бюджет чаралары (ТР бюджеты) хисабына финанслау, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2023 ел (база елы) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2023 ел (база елы) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел |
| | кысаларында остазлар бергәлеге өчен һөнәри үсешкә юнәлдерелгән очрашулар оештыру һәм уздыру | Аппараты | | | | | | | | | | |
| 1.4.8 | Коммуникатив сәясәтне гамәлгә ашыру | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре | 2025-2026 еллар | Мәгълүмати-агарту видеороликлары булдыру, видеороликлар-ны урнаштыру | - | - | 1 | 1 | - | - | 88,7 | - |
| 7 нче бурыч: Муниципаль хезмәтне норматив һәм методик яктан тәэмин итү | | | | | | | | | | | | |
| 1.7.1 | Казан шәһәре җирле үзидарә органнары остазлары һәм яңа хезмәткәрләре өчен мәгълүмати-аналитик һәм методик материаллар булдыру | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты | 2024-2026 еллар | Мәгълүмати-аналитик һәм методик материалларның нөсхәләре саны | 90 | 150 | 150 | 150 | - | 460,5 | 460,5 | 460,5 |

| № т/б | Төп чара атамасы | Башкаручылар | Төп чара-ларны башкару вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Индикатор күрсәткечләре | | | | Җирле бюджет чаралары (ТР бюджеты) хисабына финанслау, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2023 ел (база елы) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2023 ел (база елы) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел |
| 1.7.2 | Хезмәт таныклыкларын рәсмиләштерү һәм бирү | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты | 2024-2026 еллар | Хезмәт таныклыкларын бирү | + | + | + | + | - | 64,0 | 54,0 | 54,0 |
| 8 нче бирем: «Казан – иң яхшы эш бирүчеләр шәһәре» бердәм шәһәр кадрлар стратегиясен төзү кысаларындагы чараларны гамәлгә ашыру | | | | | | | | | | | | |
| 1.8.1 | Казан шәһәрендә бердәм кадрлар стратегиясен төзү өчен иң яхшы кадрлар практикалары шәһәр форумын оештыру һәм уздыру | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре | 2024-2026 еллар | «Казан – иң яхшы эш бирүчеләр шәһәре» проекты кысаларында форум үткәрү | + | - | - | + | - | - | - | - |
| 1.8.2 | Казан шәһәре халкы өчен бердәм карьера көнен оештыру һәм үткәрү | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре | 2026 ел | «Казанда карьера» чарасын үткәрү | - | - | - | + | - | - | - | - |
| **БАРЛЫГЫ** | | | | | | | | | **12 008,6** | **16 960,3** | **16 305,6** | **13 307,0** |

---